дип коры фактларга таянып сурәтләсә, Гали Чокрый күргәннәрен хис-тойгылар аша тасвирлый: "...бәгъзе көннәрдә диңгез ярына барып карап торыр идем. Һичбер көймә вә кораб күтмәенчә китеп барырдай булыр идем. Вә ләкин Кара диңгез кара аждаһа кеби дулап торыр иде. Катнар-катнар таглар кеби аунап килгәндәй булып күренеп торыр иде. Вә һәм бер артып, бер кимеп торгандай булып, бер кабарып, бер батып торгандай булып, бер якты, бер караңгы булып кыймылдап торгандай булып күренеп торыр иде. Уңга, сулга, алга таба ни кадәр текәлеп карасаң, һаман ниһаяте күренмәс иде. Бөтен дөньяны су алган икән, моның бер-бер ниһаяте бармы икән?- диеп торыр идем".

XIX гасырдагы сәяхәтнамә жанры хакында сүз йөрткәндә, аларның кайбер үсеше үзенчәлекләре турында әйтми мөмкин түгел. Арадан иң мөһиме – бу жанр кысаларында туган әдәби ядкярләрдә мактау объектының үзгәрә баруы. Элгәре чорларда иҗат ителгән сәфәрнамәләрдә мәдәни учаклар итеп Бохара яклары, гарәп илләре данланса, XIX гасыр сәяхәтнамәләрендә Россия, Европа илләренә йөз тотыла. Әлеге борылыш, Гали Чокрыйның "Хаҗнамә"се белән башланып, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими юлъязмаларында дәвам итә. Шул рәвешле, XIX йөздә сәяхәтнамә жанры үсә, үзгәреш кичерә һәм шул ук вакытта әлеге чор татар әдәбиятын сыйфат ягыннан да яңа үрләргә күтәрә.

**Әдәбият**

1. *Чернышевский Н.Г.* Полное собрание сочинений. Т. V. / Н.Г. Чернышевский. – М., 1948. – 405 с.

***Гомәров И.Г.***

## ГАЛИ ЧОКРЫЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ТАСАУВЫФ МОТИВЛАРЫ

XIX гасыр шагыйре Гали Чокрый әдәбият тарихында суфичылыкның нәкышбәндия тарикате вәкиле буларак мәгълүм. Нәкышбәндия юнәлешенең фәлсәфи җирлеген вәхдәт әш-шөһуд классик теологиясе тәшкил итә. Әлеге тарикатьнең рухи җитәкчеләреннән берсе Әхмәд Фаруки Сирхинди (1564-1624) тарафыннан пантеистик характерлы вәхдәт әл-вөҗуд теориясенә, ягъни «галәмдәге бар нәрсә дә Алла» дигән фикерләргә җавап рәвешендә канунлаштырылган вәхдәт әш-шөһуд фәлсәфәсе нигезендә «галәмдәге бар нәрсә дә Алладан» дигән караш ята.

Бу фикер әлеге мәзһәб тарафдары, XIX йөз шагыйре Гали Чокрый әсәрләрендә дә ачык чагыла. Шагыйрь үзенең «Фәйзе Гари» *(«Гариның изгелекләре»)* ядкярендә «Мөнәҗәт идәлем Хакга дәма дәм *(туктаусыз)*, Кем андыйндыр вөҗүде җөмлә галәм» дип, экзистенциаль мәсьәләләргә әлеге

теориягә нигезләнеп якын килә. Ул бу карашларын «Фосуле әрбага» *(«Елның дүрт фасылы»)*, «Замме назыйр» *(«Охшаш өстәмәләр»)* һәм башка суфичыл рухлы мөнаҗәт, назымнарында да үзенчәлекле рәвештә дәвам итә.

Автор фикеренчә, яшәеш, галәм бар булганчы, Абсолют һәм инсан бербөтенне тәшкил иткән. Шуңа күрә кеше бу фани дөньяда вакытта ук үз асылына омтылуны өмет итеп яши. Моңа, бары тик тасаувыф юлына басып, рухи остаз җитәкчелегендә заһир һәм батыйн, ягъни экзотерик һәм эзотерик гыйлемнәр туплаганнан соң, экстатик халәт аша гына ирешергә мөмкин.

Суфичылык гасырлар дәвамында Иляһи башлангыч һәм индивидуаль рухның үзара мөнәсәббәтен, бердәмлеген тасвирлау юлында әдәбиятны күпсанлы матур образлар, тәэсирле символ, метафоралар белән баетып килде. Тасаувыф әдәбияты каләм ияләре океан һәм дулкын, диңгез һәм тамчы, энҗе бөртеге һәм аны эзләүче гаувас, шәм һәм күбәләк, гөл һәм былбыл тарихы турында яратып яздылар. Болар барысы да тасаувыф фәлсәфәсенең нигез ташларыннан булган иляһи мәхәббәт хисен гәүдәләндерүдә үтемле һәм тәэсирле символ, метафоралар булдылар. «Источником душевных переживаний, - дип яза Н.Геюшов, - нашедших свое поэтическое выражение в лирических произведениях поэтов, является символ любви, которая, по мнению суфийских мыслителей, ведет путника к созерцанию истины» [2, 51].

Мистик мәхәббәт турында сүз йөрткәндә, Гали Чокрый, башка әдипләр кебек үк, үз әсәрләрендә юл (тарикать) һәм юлчы дәрвиш (салик) образлырына яратып мөрәҗәгать итә. Әлеге юл төп өч өлештән гыйбарәт: шәригать, тарикать, хакыйкать. Бу юлга баскан дәрвиш шәригать баскычында күңелен начар уй-сыйфатлардан арындыра, тарикать баскычында үзен матди дөнья белән бәйләп торучы инсани сыйфатлардан аерыла, хакыйкать дәрәҗәсендә рухи пакълеккә ирешеп, Иляһияткә якыная бара».

Суфичылык фәлсәфәсендә Аллаһыга илтүче төп юл – шәргъ, ә аннан аерылган тармагы тарик дип атала, тарикать шәригатьнең бер сукмагы буларак күзаллана. «Эта этимология показывает, – дип яза Аннемари Шиммель, – что суфии считали путь мистического обучения ответвлением от большой дороги богоданного закона, шариата, по которой, как считается должен идти каждый мусульманин» [4, 121]. Бу концепция еш кына суфилар тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең «Шәригать – минем сүзләрем (әквали), тарикать – минем эшләрем (әгъмәли), хакыйкать – минем эчке халәтем (әхвали)» дигән хәдисе белән дә ныгытыла. Димәк, ислам дине шәригать, тарикать, хакыйкатьнең үзара бәйләнешен тәэмин итүче олы бер көч тә икән.

Шәригать һәм тарикать һәм хакыйкать, –

Бу өчкә булды Ислам дине кыйсмәт.
Шәригатьне тоту – Ислам буладыр,
Тарикать эстәмәк – нурун галә нур,
Хакыйкать эстәмәк – максуд(к)а ирмәк, –

дип яза Гали Чокрый үзенең «Фәйзе Гари» *(«Гариның изгелекләре»)* исемле әдәби ядкярендә.

Шагыйрьнең «Фәйзе Гари» *(«Гариның изгелекләре»)*, «Фосуле әрбага» *(«Елның дүрт фасылы»)* кебек әдәби ядкярләреннән тыш суфичыл рухлы башка әсәрләре дә мәгълүм. Әлеге уңайдан аның Татарстан Милли китапханәсендә сакланучы кулъязмаларының берсендә урын алган шигырьләрен мисалга китерергә мөмкин. Тасаувыф әдәбиятының идея һәм этик-эстетик фикерләрен уңышлы дәвам итү ягыннан, алар арасында акростих белән язылганы һәм «бәет» дип исемләнгәне аеруча игътибарга лаек [3].

Бу шигырь Аллаһының илчесе Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхия, ягъни нәгыт жанрында иҗат ителгән. Авторның рәсүлулланы «Хакның мәзһәре» *(«Хакның тышкы чагылышы, манифестациясе»)* дип билгеләвендә дә тасаувыф фәлсәфәсе ачык чагылыш таба.

Гомумән, Мөхәммәд пәйгамбәрне идеал буларак олылау борынгы чорларга ук барып тоташа. Аның эш-гамәлләрен, сүзләрен үрнәк итү, яшәү рәвешендә вак кына детальләрдә дә аңа охшарга тырышу – бүген дә мөселманнар арасында киң таралган күренеш.

Тасаувыф әдәбиятында Мөхәммәд пәйгамбәр образы Хак Тәгалә тарафыннан галәмнең, барлыкка китерүенә сәбәпче һәм соңгы максаты буларак тасвирлана. Аның йөзендә Аллаһы үзенең иляһи матурлыгын чагылдыра, үз-үзен манифестацияли дип санала. Мөхәммәд – Илаһият нурланышының дәвамчысы, галәмгә, дөньяга килгән беренче Җан. Барлык башка пәйгамбәрләр аның нурыннан тудырылган. Бу хакта гарәп галиме Гәднан Хөсәен әл-Гавади «Суфичылык вәкилләре Мәхәббәтнең Акылдан аерылып чыгуын гел искәртеп килделәр һәм моны Мөхәммәд – Аллаһының сөеклесе дигән фикергә нигезләнеп расладылар. Ул – беренче нур. Аннан мәңгелек аша калган пәйгамбәрләрнең нурлары, илаһи Матурлык серләре таралыш таба», – дип язды үзенең «Суфичылык шигыре» исемле хезмәтендә. [1, 174]

Мукатил, Мансур әл-Хәллаҗ, Сәхл әт-Тустари, Гаттар, Ибн Гарәби кебек әдип-философларның хезмәтләрендә дә Пәйгамбәр образы нәкъ шул рәвешчә тасвирлана. Ибн Гарәби Тәңренең җирдәге әлеге илчесен Камил Инсан (әл-инсан әл-камил) белән тиңләштерә. Шуңа нигезләнеп, тасаувыфның соңгы чорларында суфилар тарафыннан «фәна фир-рәсүл»

тәгълиматенә нигез салына.

Әлеге теория буенча, дәрвишнең башта үз рухи җитәкчесе шәехкә (фәна фиш-шәех), аннан Аллаһының хак рәсүле – Мөхәммәд пәйгамбәргә буйсынуы, аның белән рухи кушылуы (фәна фир-рәсүл) Илаһи затка илтүче мистик юлның төрле этаплары буларак төсмерләнә. Бу фәлсәфи карашлар Гали Чокрыйның без алдарак искә алган әсәренә дә үтеп кергән.

Хак Тәгалә берлә гәр барыб җитсәм сиңа,
Кил кабул ит фазлың илә, йә, шәфигъ әл-мөзнибин.
Мең җаным булса, барын бән юлыңа кылсам фида,
Кәмтәрен һәдия санармын, йә, шәфигъ әл-мөзнибин
*(Кимчелеген бүләк санармын, я, гөнаһлыларны яклаучы)*, -

дип яза шагыйрь.

Нәгыт жанрындагы әдәби ядкярләрнең классик үрнәге булып гарәп әдипләре Кәгъб ибне Зөхәйр һәм Шәрәфеддин Мөхәммәд әл-Бусири (1212-1294) каләменнән төшкән «Касидәт әл-Бурда» *(«Плащ турында касидә»)* поэмалары санала. Җәлаледдин Руми, Хакани, Мир Дард, Сөләйман Чәләби, Йуныс Әмрә, Шәмседдин Зәки, Гали Чокрый һәм тасаувыф әдәбиятының башка бик күп каләм ияләренең иҗатларын Пәйгамбәргә багышланган шигъри юллардан башка күз алдына да китереп булмый.

Шунысы үзенчәлекле, бу төр әсәрләрдә авторларның Аллага мәдхия укыганда аның кодрәтенә, бөеклегенә соклanулары алгы планда торса, Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать иткәндә моң-зарларның, хис-кичерешләрнең ихласлыгы, лиризмның көчле тәэсире аша рухи пакълеккә омтылу мотивы үзен нык сиздерә.

Лотфың илә бер нәзар *(караш)* кыл, фазлың илә бир хәбәр,
Фәйзың илә бер әсәр *(билге)* бир, йә шәфигъ әл-мөзнибин...
Кальбемә рух риахын *(җилләрен)* сорыйм серләр салыб,
Сиратымны сираб иткел, йә шәфигъ әл-мөзнибин
*(Тормышымның сусавын бас, я, гөнаһлыларны яклаучы)*, -

дип яза Гали Чокрый.

Әсәрдә Пәйгамбәр образының рухи камиллеге лирик геройның мөрәҗәгать-ялваруларына мөнәсәбәттә ачыла бара һәм әхлакый бәянең иң югары күтәрелеш ноктасы булып формалаша. Биредә автор, суфичылык әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, үзен «гасый» *(«кимчелекле»),* «хәкыйрь» *(«кызганыч»),* «шәнигъ әл-мөзнибин» *(«гөнаһлыларның гөнаһлысы»)* дип атый, ә рәсүлуллага зур хөрмәт белән «йә, хәбиб әл-мөстиган» *(«Аллаһының сөеклесе»),* «шәфигъ әл-мөзнибин» *(«гөнаһлыларны яклаучы»)* кебек эпитетлар кулланып мөрәҗәгать итә. Шигырьдәге мондый антиномияләр тезмәсе лирик геройның әхлакый камиллек чыганагы –

Мөхәммәд пәйгамбәргә омтылуы аша рухи катарсиска ирешүен күрсәтә. Димәк, әсәрдә суфичылыкның Иляһи мәхәббәт концепциясе белән тыгыз бәйләнештә торучы рухи сафлык тәгълиматы Пәйгамбәр образы ярдәмендә ачылыш таба.

Җыеп әйткәндә, шагыйрьнең мондый әсәрләре вәхдәт әш-шөхуд фәлсәфәсенә нигезләнгән төрки-татар классик тасаувыф әдәбияты традицияләрен дәвам итә. Идея-эстетик карашлар һәм сәнгатьчә сурәтләү чаралары ягыннан XIX йөз татар әдәбиятының сыйфат дәрәҗәсен бер баскычка югары күтәрүдә дә аларның өлеше зур. Әйтик, «Фосуле әрбага» *(«Елның дүрт фасылы»)* ядкярен Гали Чокрый иҗатының гына түгел, гасыр поэзиясенең уңышлы үрнәкләреннән дип санарга мөмкин.

**Әдәбият**

1. *Гаднән Хөсәен әл-Гавади.* Суфи шигърият. – Багдад, 1989. – 274 б. (гарәп телендә).
2. *Геюшов Н.Д.* Символ любви у Дж.Руми и М.Физули // Советская тюркология. – 1988. – № 2. – С. 51-52.
3. Татарстан Милли китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге. 600 т.
4. *Шиммель А.* Мир исламского мистицизма. – М.: Алетейа, Энигма, 2000. – 416 с.

***Груздева Е.А.***

## ОБРАЗ ПРОСТАКА В ТВОРЧЕСТВЕ МАРКА ТВЕНА 1870-х ГОДОВ

До 1874 года имя Марка Твена ассоциировалось для большинства читателей с его юмористическими рассказами и очерками. В начале 1870-х годов писатель уходит от традиций западного юмора и обращается к отражению современности, к жизненной достоверности. У него складывается критико-реалистическое восприятие американской действительности того времени: Твен находит недостатки устройства жизни в Америке и начинает открыто рассуждать о них в своем первом романе «Позолоченный век» (1874), более того, чтобы лучше понять и оценить реалии США он повторно отправляется в путешествие в «чужой» европейский мир, результатом которого является книга путевых очерков «Пешком по Европе» (1878).

Роман «Позолоченный век» – единственный роман Твена, посвященный современности. Тему книги подчеркивает подзаголовок «Повесть наших дней». Это произведение американского писателя оказалось настолько созвучным времени, что породило название целой эпохе – 1870-е годы в США историки называют «позолоченным веком». В романе Твена воссоздается дух времени – это был авантюрный период политической и экономической жизни США, период зарождения великих финансовых объединений. Быстрое экономическое развитие сопровождалось разного рода